| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.03.2023 г.Лениногорск № 12

2023 елда Лениногорск муниципаль районы муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча Лениногорск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында һәм муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин, дип билгеләргә.

2.Әлеге карарның 1 пункты «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары С.В. Тимаковка йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Советы рәисе Р.Г.Хөсәенов